## Тарихыбызны баетучылар

Казанга татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җыелды. Әлегә кадәр алар конференция, җыеннар форматында узган чараларда катнашып килсәләр, бу юлы мондый чара зуррак масштабта үтте. I Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр съездында илнең 35 төбәгеннән 250 делегат катнашты. 4 БИТ

## Пенсионерларны нәрсә борчый?

Пенсия – мәңгелек темадыр, мөгаен. Бу өлкәдәге үзгәрешләр турында күпме генә язылса да, Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге белгечләре көн саен халыкны кызыксындырган сорауларга җавап биреп торса да, аларның бетәсе юк. «Бердәм Россия» партиясенең төбәкара иҗтимагый кабул итүләр бүлмәсендә дә нәкъ менә шул темага сөйләштеләр. 5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри Казан

татмедиа

Сишәмбе | 28.03.2017 | №32 (5794)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

# СЕБЕРКЕ, ТЫРМАНЫҢ ДӘРӘҖӘЛЕ ЧАГЫ

**Казанда 1 апрельдән 31 майга кадәр санитар икеайлык үткәрелә. Гомумшәһәр өмәсе – 29 апрельдә.**

**Дамир БӘДРИЕВ**

– Урамнарның юл буйларындагы 17 миллион квадрат метр яшеллекне, 3800дән артык ишегалдын җыештыру бурычы тора, – дип хәбәр итте шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – тышкы төзекләндерү комитеты рәисе Игорь Куляжев кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Беррәттән, гомумисәптә 130 километр рәшәткә, 4 мең ут баганасы, 300 светофор корылмасы чистартып-буяп чыгылачак.

– Казанда элек кыш дәвамында 152 урында рөхсәтсез чүплек өемнәре барлыкка китерелә иде. Җаваплылык күтәрелә бара, тик шулай да 32 урында чүплек кабат табылды, шуларның алтысы – зур күләмдәгеләр, – дип, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Денис Калинкин казанлыларны һәм предприятиеләрне санитар икеайлыкта янә актив катнашырга чакырды.

kzn.ru

Районнар хакимиятләреннән, шулай ук торактан файдалану идарәләреннән (ЖЭУ) чүп капчыклары һәм эш коралларын соратып алып, кулланып торырга мөмкин.

Казанның тышкы төзекләндерү кагыйдәләре буенча йөк машиналары тәгәрмәчләре төзелеш урыннарыннан юдырылып чыгарылырга тиеш. «Карттранс», «Партнер и К», «Гранада», «Ак Барс Строй», «Витязь», «КамаСтройИнвест», «Грейт-Строй», «АйСиЭл», «Поволжская ремонтно-строительная компания» оешмаларының кайбер төзелеш мәйданнарында бу таләп үтәлми.

– Аларның җитәкчеләрен – 50 мең сумга, ә оешмаларын бер миллион сумга кадәр штраф көтә, – дип кисәтте административ-техник инспекция идарәсе җитәкчесе Әлфир Шәмсетдинов.

– Соңгы елларда Казанда юлларны кардан чистарту яхшырды. Әлбәттә, шәһәр читендәге урамнарда һәм бистәләрдә яшәүчеләр бу сүз белән килешмәс. Ләкин башта 1нче һәм 2нче категориядәге юллар җыештырыла, – дип, докладчыны тулыландырды шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Денис Калинкин.

– Казанда 20 миллион квадрат метр юл өслеген җыештырырга кирәк. Бу бик зур мәйдан. Кышкы чорда юлларда эшләү өчен 1550 кеше кирәк. Тик хезмәт хакы аз, ә эш шактый авыр булганлыктан, штат яртылаш кына туплана. Урам юлларын җыештыруда 560 берәмлек техника файдаланыла, әмма алар да 40 процентка искерде, – дип, мәсьәләне аңлатты Игорь Куляжев.

Шәһәр Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе җитәкчесе Әлфир Шәмсетдинов әйткәнчә, кышкы чорда үз территорияләрен тиешенчә җыештырмаганнары өчен, юридик затларга 334 административ беркетмә тутырылган.

– «Пятерочка» кибетләре челтәрен берләштергән «Агроторг» белән «Магнит» кибетләре челтәрен берләштергән «Тандер» җәмгыятьләре мәсьәләгә аеруча битарафлык күрсәттеләр, – диде Әлфир Шәмсетдинов.

Түбәләрне кардан арындырмаган өчен «Авиатөзелеш районы торак-коммуналь хуҗалыгы», «Мәскәү районы торак-коммуналь хуҗалыгы», «Слобода» идарәче компанияләренә, «Алика» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә, «Телевышка» торактан файдалану идарәсенә дә штраф «чәпелгән».

Сабантуй

## көне билгеле

**Быелгы милли бәйрәмнәрне Америка Кушма Штатларындагы Флоридада яшәүче татарлар башлап җибәрде. 19 март көнне милләттәшләребез Сабан туен билгеләп узды.**

Бу көннәрдә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов быелгы Сабан туен бәйрәм итү көне турындагы карарга кул куйды. Карар нигезендә, авылларда һәм район үзәкләрендә бәйрәм 1 һәм 2 июль көннәрендә узачак. Чаллыда – 8 июльдә, ә Казанда Сабан туен 15 июльдә үткәрергә ниятлиләр. Соңгы елларда популярлашкан Бөтенроссия татар авыллары Сабан туен быел 15-16 июль көннәрендә Пенза өлкәсе Урта Әлзән авылында уздырырга җыеналар. Урта Әлзән – Россиядә иң зур татар авылларының берсе, анда 9 меңгә якын кеше яши. Бәйрәм мәйданы 30 гектарны били, Сабан туена 50 меңнән артык кунак җыелыр дип көтелә. XVII Федераль Сабан туен уздыру хокукы исә быел Әстерханга бирелде. Ул 12-13 май көннәрендә узачак.

Быел тагын бер яңалык – Бөтендөнья Татар конгрессы хәбәр итүенчә, беренче тапкыр Ык буе авыллары Сабан туен оештырырга уйлыйлар. Ул 14 район халкын берләштерәчәк. Әлеге проект – Башкортстанда яшәүче татар эшмәкәрләре тәкъдиме. Милли бәйрәм 22 июльдә Башкортстан Республикасының Туймазы районы Төмәнәк авылында үтәр дип планлаштырыла.

# Беренче чиратта дини оешмаларга ярдәм итәчәкләр

**«Татфондбанк» һәм «Интехбанк» клиентларына ярдәм итү фонды» әле 21 мартта гына оешса да, инде шактый эш башкарылырга өлгергән. Фондтагы яңалыклар турында аның җитәкчесе Булат Бакеев «Татар-информ»да узган матбугат конференциясендә сөйләде.**

**Эльвира МОЗАФФАР**

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Баштарак фондны оештыручы дүрт эшмәкәрнең өчесе сер булып сакланса, бу юлы аларның исемнәрен әйтергә булдылар. Радик Сафин, Рөстәм Ибнеев, Илдар Сәфәргалиев, Булат Бакеев берләшеп банкротлыкка чыккан банк клиентларына ярдәм итәргә җыеналар. Башта оешма хәйрия фонды формасында эшләячәк. Булат Бакеев әйтүенчә, хәзер алар Татарстандагы компанияләр белән сөйләшү эшләре алып бара. Тамчыдан күл җыела дигәндәй, аз гына ярдәмгә дә риза фонд вәкилләре.

«Татфондбанк» клиентларына килгән зыянны каплар өчен 60 миллиард сумлап акча таләп ителә. «Интехбанк», «ТФБ Финанс» клиентларын, юридик затларны да кушсаң, таләп ителгән сумма 100 миллиард сумга җыела. Дөрес, безнең фонд барысын да канәгатьләндерә алмаячак. Барлык сумманың 10 миллиардын җыя алсак та, нәтиҗәле булыр иде дип уйлыйм. Ничек кенә булмасын, беренче чиратта, юридик яктан төгәллек белән һәм гадел эшләячәкбез, – ди Булат Бакеев.

Фондка ярдәм кулы сузарга әзер оешмалар инде табылган. Тик аларның күпме акча күчерергә теләвен һәм кемнәр икәнен Булат әфәнде әйтергә теләмәде. Уенын-чынын бергә кушып: «Күз тидерүдән куркам», – диде.

Фонд хәзер эшне башлау өчен бина эзли. Дөрес, монда клиентларны кабул итмәячәкләр, бердә документларны тикшерү, мәгълүматны эшкәртү белән шөгыльләнәчәкләр. Ә банктан зыян күргәннәр фондка махсус сайт аша мөрәҗәгать итә алачак. Сайт әлегә эшләнә генә. Ике атнадан соң бәлки эшли дә башлар. Аның ышанычлы, чыдам булуы кирәк, шуңа да барысын да җентекләп әзерлиләр. Фонд эшенә Татарстанның Икътисад, Сәламәтлек саклау, Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыкларын да җәлеп итәргә җыеналар. Уртак хезмәттәшлеккә өндәп язылган хатлар министрлыкларга юлланган.

Беренче эш итеп, фонд дини оешмаларга ярдәм итәргә җыена. Банклардан зыян күргән мондый оешмалар күп түгел. Алар күргән зыян да берничә миллион сум белән генә исәпләнә.

– Шуңа да эшне азчылыкны тәшкил иткән дини оешмалардан башлау безнең өчен дә тәҗрибә булыр иде, бу мөмкинлекләребезне сынап карау өчен дә файдалы, – ди Булат Бакеев.

Эшмәкәрләр оештырган әлеге фонд Россиядә бердәнбер. Дөрес, финанс пирамидалары «корбан»нары, банкротлыкка чыккан банк клиентлары белән эшләүче бер оешма билгеле. Әмма ул Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы оешканчы эшләгән банк кертемчеләренә ярдәм күрсәтә. Шуңа да «Татфондбанк» һәм «Интехбанк» клиентларына ярдәм итү фондының үрнәк алырлык, тәҗрибә уртаклашырлык кешеләре дә юк. 23 ел финанс-кредит буенча укыткан мөгаллим, эшмәкәр Булат Бакеев үз белеменә, иптәшләренең ярдәменә генә таяна. Сүз уңаеннан, ул үзе дә банктан зыян күрүчеләр арасында. «Татфондбанк»та аның 35 меңләп, «Интехбанк»та 870 меңләп акчасы янган.

– Банклар белән килеп чыккан вазгыятьтә гаеплене озаклап эзләргә була, ләкин бу сораулар инде үткәннәргә кагыла, үткән эшкә салават. Хәзер киләчәк турында уйларга кирәк. Урамда яз, кояш! – дип, позитив булырга өнди Булат Бакеев.

**КОРЫЛТАЙ АЛДЫННАН**

# Татарстан халыклары съездында 700дән артык делегат катнашачак

**2017 елның 22 апрелендә узачак әлеге зур масштабтагы форумга әзерлек тулы көченә бара.**

Әлеге вакытта республиканың барлык муниципаль районнарында дәүләт милли сәясәте Концепциясен тормышка ашыру һәм съездга делегатлар сайлау буенча иҗтимагый советның киңәйтелгән утырышлары уза. Шундый 37 утырыш инде узган. Муниципалитетлардан делегатларны билгеләү процессы 30 мартка кадәр тәмамланачак дип планлаштырыла. Ә милли-мәдәни автономияләр (республикада алар 36) үз делегатларын сайлап бетергән инде. Татарстан халыклары съездында территорияләрдән һәм милли-мәдәни оешмалардан барлыгы 730 делегат катнашачак. Моннан тыш Россия төбәкләреннән, шулай ук ерак һәм якын чит илләрдән кунаклар чакырылачак, дип яза addnt.ru. Татарстан халыклары съездын республика Президенты Рөстәм Миңнеханов ачып җибәрәчәк. Дәүләт Советы рәисе, оештыру комитеты рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, съезд республикабызның иҗтимагый-сәяси тормышындагы бик мөһим вакыйга булып тора.

– Моңа кадәр 1992 һәм 2007 елларда узган Татарстан халыклары съезды республикадагы милләтара һәм динара үсешкә нык тәэсир итте, милли-мәдәни хәрәкәтне оештыруга үзгәрешләр кертте, – диде ул.

Төп форумны оештырудан тыш, Татарстан халыклары съезды кысаларында бик күп чаралар планлаштырыла. Әйтик, съездга кадәр «Халыклар һәм традицияләр» татар киносы көннәре, «Звонкая капель» республикакүләм балалар фольклор коллективлары фестиваленең гала-концерты, милли әдәбият күргәзмәләре, Милли музейда очрашулар, «Рус теленнән тотальдиктант» халыкара мәгариф акциясе, татар теленнән халыкара олимпиада һәм башкалар узачак. Съезд үткән көнне Татарстанда яшәүче халыкларның кулланма-гамәли сәнгать күргәзмәсе, Халыклар дуслыгы йортлары экспозициясе, «Күпмилләтле Татарстан» һәм «Без – Россиянең бер өлеше» фотокүргәзмәләре ачылачак.

**Александр Акримов,** Кайбыч районы:

*– Татарстан халыклары съездына делегат булып сайлануым миңа җаваплылык хисе өсти. Анда телне саклап калу мәсьәләләре буенча сөйләшү дә булыр дип өметләнәм. Бүгенге көндә тел югалу проблемасы бөтен милләтләрне дә борчый, шул исәптән безне – мәлки керәшеннәрен дә. Кайбыч районында яшәүчеләрне «Мәлки керәшеннәре» дип атап йөртәләр. Безнең керәшен авыллары тарихы бик аз өйрәнелгән. Аның тарихы гаять дәрәҗәдә кызыклы, менә шуны өйрәнәсе бар.*

**Алексей Калуков,** Аксубай районының чуваш автономиясе җитәкчесе:

*– Безнең республикада милләтләрне үстерү буенча бик күп эшләр эшләнә, махсус дәүләт программалары бар. Милли бәйрәмнәребез билгеле бер милләт эчендә генә калмыйча, халыкара чарага әйләнде дияргә була. Аларны зур итеп уздыра башладык. Милләтләр яшәеше белән кызыксынучылар күп, телевидениедән гел килеп тапшырулар эшләп китәләр. Телевизордан һәрдаим күрсәтәләр. Яшь буын да моны күреп, үз милләтләре белән горурланып үсә.*

КАПИТАЛЬ РЕМОНТ

# Мәктәпләр ялт итте, чиратта – балалар бакчалары

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов теләктәшлегендә, 2012 елда республикада мәктәпләрне капиталь төзекләндерү программасы старт алган иде. Быелның 15 августында финишка җитәчәкбез, боерган булса.**

**Дамир БӘДРИЕВ**

Автор фотосы

– Биш ел эчендә 778 мәгариф учреждениесе комплексы төзекләндерелде. Болар: 673 муниципаль һәм 42 коррекция, ягъни начар күрүчеләр мәктәбе, 63 балалар бакчасы. Эшләр башкаруга 12 миллиард 473 миллион 309,74 мең сум акча тотылды, – дип хисап тотты республиканың төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының беренче урынбасары Алексей Фролов «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Программага төзелүенә 30 елдан артык булган мәктәпләр алынды. Беренче елгы исемлеккә кергән мәктәпләрдә эшләүче укытучыларның һәм ата-аналарның сөенечләре бүгенгедәй хәтердә. Казан мәктәпләре директорлары республика Президентына әле булса рәхмәт укый. Ләкин 2013 елдагы исемлектәгеләрдән көнләшү дә килеп чыкты.

– Башта мәктәпнең түбәсен, ишекләрен, инженерлык челтәрен төзәтү генә каралган иде. Икенче елдан бинаның тышкы дивары төзекләндерүгә алынды. Баштагы мәктәпләргә «кул селтәп» калдырмадык. Төзекләндерү ихтыяҗы булганнарының тышкы диварлары җирле финанс чыганакларына тәртипкә китерелде, – диде Алексей Фролов.

Республикада быел 146 мәгариф учреждениесе комплексы төзекләндерелә.

– Мәктәпләрне колачлап чыктык, дип әйтергә була. Хәзер балалар бакчаларын капиталь ремонтлауга күчәбез. Быел 110 балалар бакчасы төзекләндерелә, – диде Алексей Фролов. – Эшнең сыйфатына нык игътибар биреләчәк.

Мәктәп директорларны ачык һавадагы спорт мәйданчыгының да төзекләндерелүен бик теләгәннәр иде. Тик бу эш программа исемлегендә юк. Алексей Фролов әйткәнчә, балалар бакчалары бииналары гына төзекләндерелә, ә төркемнәрнең уен мәйданчыкларындагы корылмаларны яңарту каралмаган. Балалар бакчаларын төзекләндерү программасы әле башлангыч этапта гына. Биналар белән беррәттән, төркемнәрнең ачык һавадагы уен мәйданчыклары корылмаларын да яңартуны эшләр исемлегенә кертәсе иде.

– Әйе, балалар бакчаларында асфальт катламнары да, уен корылмалары да искергән, ләкин төзекләндерү исемлегендә бина гына, – дип аңлатты Алексей Фролов.

Татарстанда 2014 елдан башлап ресурс үзәкләренә, ягъни училищелар һәм техникумнар биналарына да капиталь ремонт үткәрелә. Өч елда 27 ресурс үзәге яңартылган. Быел ун учреждение исемлеккә алынган, унысында да эш башланган. Мисал өчен, башкаладагы мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы, радиомеханика көллияте, сәүдә-икътисад техникумы, коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте төзекләндерелә.

– Заводлар һәм предприятиеләр генә түгел, төзелеш оешмалары да үзләренә эшче кадрлар әзерләүче ресурс үзәкләренә шефлык ярдәме күрсәтәләр, – диде Алексей Фролов.

tatar-inform.ru

# ЮГАЛТУ

**Бу елларда Казан халкы дары заводындагы янгын вакытында батырларча һәлак булган Эдуард Илларионов белән хушлашты. 27 март көнне мәрхүмне туган җире Мари Элда җирләделәр.**

Эдуард – Мари Эл республикасы журналисты, шагыйрь Вадим Илларионовның улы. Әтисе бик иртә үлгән. Өч бала белән тол калган әнисе гаилә дилбегәсен ялгызы гына тарта. Балачактан янгын сүндерүче булырга хыялланган егет гомеренең соңгы мизгеленә кадәр Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгында хезмәт итә.

– Балаларымны гадел, намуслы, яхшы кеше булсын дип үстердем. Эдуард иң олысы иде. Тәпчекләргә әтиләре урынына калды. Энесенә, сеңлесенә һәрвакыт ярдәм итте. Энесе дә, сеңлесе дә тормышта, ә Эдуард гаиләкорырга да өлгермәде, – диде әнисе Фаина Илларионова.

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматлары буенча, түбән һәм урта дәрәҗәдәге янгыннардан тыш, Илларионов дары заводындагы тагын өч җитди гадәттән тыш хәлләрдә алгы рәтләрдә булган.

– Бу юлы да, үз гомере бәрабәренә дусларының, хезмәттәшләренең генә түгел, дары заводында эшләүчеләрнең дә гомерен саклап калды, – диде Казан дары заводы генераль директоры Хәлил Гыйниятов.

Исегезгә төшерәбез, Казанда дары заводында чыккан янгынны сүндерүгә беренче булып Эдуард Илларионов расчеты килеп җитә. Шартлау аркасында, Эдуард Илларионов җәрәхәт ала һәм ашыгыч ярдәм машинасында гомере өзелә.

Разведкага кадәр ул үз кул астындагыларга йөкләмәләр биреп өлгергән. Шуның нәтиҗәсендә, янгын сүндерүдә нәтиҗәле эш башкарыла, гадәттән тыш хәл янгын-коткару хезмәткәрләре, заводтагыларның күпләп җәрәхәт алуына, үлеменә китерми.

Эдуард Илларионов 1980 елның 15 февралендә туган. Ул бары 37 ел яшәп кала. Россия Президенты Владимир Путин боерыгы буенча, Эдуард Илларионов, үлгәннән соң, Россия Федерациясенең Дәүләт бүләге – «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән.

Ул шулай ук Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Күрсәткән хезмәт өчен» күкрәк билгесе, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Маршал Василий Чуйков» истәлек медале, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Янгындагы батырлыгы өчен» медале, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Хезмәттәге уңышлары өчен» III дәрәҗә медале, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Хезмәттәге уңышлары өчен» II дәрәҗә медале белән бүләкләнгән. Эчке эшләр капитаны Эдуард Илларионов, үлгәннән соң, Батырлык орденына тәкъдим ителә.

**Чыганак – «Татар-информ».**

КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК

# Белемле кулланучы бул

**Торак-коммуналь тармак исәп-хисап гамәлләре белән бәйле. Акча катнашкан эштә нәрсәнең нәрсәгә икәнлеген белеп тору, тиеннәрне санау хәерле.**

– Халыкның торак-коммуналь хуҗалыкка кагылышлы мәсьәләдә белеме түбән. Халык күпфатирлы йортларда милекчеләр советлары оештыруда активлык күрсәтми. Гомумйорт ихтыяҗлары (ОДН) түләүләрен билгеләүдә, коммуналь хезмәтләр өчен исәп-хисап чыгаруда үтә күренмәлелек җитми, – диде «Төбәк җәмәгатьчелек контроле үзәге» башкаручы директоры Дмитрий Романов «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Казанның Лобачевский урамындагы 10в йортында урнашкан әлеге үзәк белгечләре торак-коммуналь тармакка кагылышлы сорауларга җавап табуда, четерекле мәсьәләләрне чишүдә бушлай ярдәм күрсәтә. Халык белән очрашуларда, мәктәпләрдә һәм ВУЗларда торак-коммуналь белемнәр пропагандалана.

Апрель аенда «Белемле кулланучы мәктәбе»нең чираттагы бушлай курслары башлана. Курсларга үзәкнең Лобачевский урамындагы офисында язылырга мөмкин. «Төбәк җәмәгатьчелек контроле үзәге»нең «кайнар элемтә» телефоны: **(843) 236-29-97.** Бу телефон буенча шалтыратуларны дүшәмбе-җомга көннәрендә 9.00-18.00 сәгатьләрдә кабул итәләр.

– Кулланучылар белемен күтәрү максатында, онлайн-дәресләр үткәрәбез. Җәмәгать торак инспекторы проектын башларга ниятлибез, – диде Дмитрий Романов.

«Төбәк җәмәгатьчелек контроле үзәге» рәисе Михаил Застелла күпфатирлы йортларга үз җылылык пунктларын (ИТП) көйләү программасын хуплый.

– Үзәк җылылык пунктларыннан торбалар буйлап килгәндә, җылы суның температурасы югала. Йортның үз җылылык пункты булу мондый югалтулардан коткара. Үз җылылык пунктлары көйләнелгән йортлардагы кешеләрдән сорашып белештем. Алар җылы су өчен түләүләрнең кимегәнлеген әйтте, – диде Михаил Застелла.

Ул – идарәче компанияләргә бирелә торган лицензияләрне яңартып тору тарафдары. Михаил Застелла фикеренчә, идарәче компания халыкка торак-коммуналь хезмәтләрне тиешле дәрәҗәдә оештыра алмый икән, димәк, андыйларның лицензиясен алырга кирәк.

**Рәдиф КАРАГАЙ.**

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

# Тарихыбызны баетучылар

**Казанга татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җыелды. Әлегә кадәр алар конференция, җыеннар форматында узган чараларда катнашып килсәләр, бу юлы мондый чара зуррак масштабта үтте. I Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр съездында илнең 35 төбәгеннән 250 делегат катнашты.**

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**

Съездның пленар утырышында чыгыш ясаган Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова чарада катнашучыларга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның мөрәҗәгатен укыды. «Бүгенге глобальләшү шартларында халкыбызның телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калу, аларны киләсе буынга җиткерү мәсьәләсе – иң җитди проблемалар рәтендә. Шуңа да бай мирасыбызны өйрәнү, аны туплау, фәнни анализлау һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерү мөһим бурычлар булып тора. Шунысы шатландыра: һәвәскәр тарихчыларыбыз татар тарихы белән бәйле эзләнүләрен беркайчан да туктатмады. Авыллар тарихын өйрәнү хәрәкәте көчле бер шаукым булып күтәрелде. Нәсел шәҗәрәләре белән кызыксынучылар да артты. Татар тарихы чылбыры киләчәктә дә өзелмәс дип ышанам» диелә мөрәҗәгатьтә. Римма Ратникова төбәк тарихын өйрәнүчеләргә республика җитәкчесе исеменнән рәхмәтен җиткерде.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров та төбәк тарихын өйрәнүнең бик җитди һәм катлаулы мәсьәлә икәнен билгеләп үтте.

– Соңгы елларда татар авыллары тарихын өйрәнеп язган бик күп китаплар нәшер ителде. Бу – халкыбызның зур байлыгы булып тора. Киләчәк буыннарга да калачак байлык бу, – диде ул.

Бөтенроссия төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе Камил Әбләзов үзенең чыгышында татарлар тарихын өйрәну тиешле дәрәҗәдә булмавын белдерде. Татар тарихын татарларга караганда кытайлар күбрәк өйрәнә, диде ул.

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев фикеренчә, төбәкләр тарихын профессиональ тарихчылар һәвәскәрләр белән берләшеп язарга тиеш.

– Алар бергә эшләгәндә генә югары нәтиҗәләргә ирешеп була. Берсе күреп алмаган тарихи нечкәлекне икенчесе тотып алырга мөмкин. Сугышны да бит генерал үзенчә, ә солдат үзенчә күрә, – дип белдерде ул.

Искәндәр Гыйләҗев залда утыручыларга, безнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты белән элемтәдә торсагыз иде, бу барыбызга да файдалы булачак, дип тә мөрәҗәгать итте.

Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков та татар төбәкләрен өйрәнү эшендә академик институтларның үзара берләшеп эшләве яклы.

– Мондый зур эшне галимнәрдән башка эшләп булмый. Сер түгел, институтлар һәрберсе аерым эшләргә күнеккән. Татар авыллары тарихын аерым язып булмый. XVI гасырдан түбәнрәк төшкән вакытта археологлар да кирәк, – диде ул.





Галим бу эшкә фермерлар, эшмәкәрләрне дә җәлеп итәргә кирәк, алар матди яктан булыша алалар, дигән фикердә тора.

– Бөтентатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр оешмасы кул астында чыгачак «Туган җир» журналында уңышлы эшмәкәрләр турында сәхифә дә булырга тиеш дип уйлыйбыз. Журнал турында сүз чыккан икән, аның электрон версиясе дә булырга тиеш. Бу яшьләр өчен кулай булачак, – ди Дамир Исхаков.

Россия ислам институты ректоры Рафыйк Мөхәммәтшин авыллар тарихын язганда мәчет, мәдрәсәләр тарихларын да язуларын үтенде.

– Милли аңны формалаштыруда төбәкләр тарихын язучыларның роле зур. Аларның хезмәтләрен укып, үз милләтең, Ватаның белән горурланасың. Төбәкләрдән бик күп күренекле шәхесләр чыккан. Алар үз чорының атаклы мәдрәсәләрендә укыган. Сез китапларыгызда шулар турында да язсагыз иде, – диде ул.

Тарих фәннәре кандидаты Альберт Борһанов «Туган җир» журналындагы язмаларның аннотациясен русча һәм инглизчә дә бирергә кирәк дигән фикердә тора.

– Төбәк тарихын язуга килгәндә, бу эштә өч союзник булырга тиеш. Беренчесе – галимнәр, тарихның методикасын беләләр, ләкин авылда яшәмиләр, шуңа да материаллар аларга якын түгел. Икенчесе – төбәкне өйрәнүчеләр, алар авылда яшәп материалларны туплыйлар. Өченчесе – җирле хакимият, алар оештыру һәм финанс мәсьәләсендә ярдәм итәчәк. Эшебез өч юнәлештә барырга тиеш: төбәкләр буенча материалларны өйрәнү, җыю, туплау; аларны саклау; реаль тормышка җиткерү, әйтик, туризм, тәрбия өлкәсендә куллану, – ди ул.

Съезд эшендә катнашкан – бик күп авыллар тарихларын язган Фәүзия Бәйрәмова ерак төбәкләрдәге татар тарихы яхшылап өйрәнелмәвенә борчыла.

– Сахалин, Урал, Приморье краен руслар гына өйрәнгән. Татарларның сөрген тарихы, көчләп чукындырылу тарихын өйрәнгәнебез юк. Материаллар архивларда җитәрлек, бу бик зур һәм әһәмиятле эш. Институтларда кандидатлык, докторлык диссертацияләрен язучыларга моны мәҗбүри тема итеп куярга кирәк. Язучыларны да бу эшкә җәлеп итик, – диде ул.

Утырыш ахырында Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр оешмасы төзелде.

---

**Ришат Рәхимов**, Төмән өлкәсе:

– Себер татарлары мәдәниятен өйрәнүче кеше буларак, коллегаларым белән аралашырга, алар белән танышырга дип килдем. Икенчедән, әлеге чара тарихчыларга алга таба тагын да активлашырга бер этәргеч булачак. Хөкүмәттәгеләр дә безгә таба йөз белән борылырлар, татар халкы тарихын өйрәнүдә безгә ярдәм күрсәтерләр дип өметләнәм. Бөтен төбәкләрдә дә татар халкы тарихы белән шөгыльләнүче академик структуралар юк, шул исәптән Төмәндә дә. Шуңа да безгә җирле хакимиятләрнең, Казанның ярдәме кирәк.

**Ромэн Гозәеров**, Мәскәү өлкәсе:

– Мәскәү өлкәсе татарлары турында китаплар язам. Бу эшкә мин милли күтәрелешләр башланган 90нчы елларда тотындым. Тумышым белән Башкортстаннан. Крайны өйрәнү буенча кызыклы фикерләр, идеяләр ишетәсем килә, әмма үзем өчен яңа әйберләр таптым дип әйтә алмыйм. Минем үземә татарларның башка милләт вәкилләре белән үзара мөнәсәбәте кызык. Россия – күпмилләтле ил. Подольскида Сабан туе да зурлап уздырыла. Ул Талалихин паркында узә. Советлар Союзы герое Виктор Талалихинның иң якын дусты Гафуров фамилияле татар кешесе булган. Рус һәм татар солдатының дуслыгы мине бик кызыксындырды.

Без һәвәскәр тарихчыларның бер проблемасы бар: китапларны язабыз, ә чыгарырга акча юк. Матди ярдәм күрсәтелсен иде. Моның белән дәүләт органы шөгыльләнергә тиеш дип уйлыйм. Элек бит татар байлары мәдрәсәләр салган, китаплар чыгарган. Менә шундый кешеләр табылсын иде.

**Айдар Басыйров,** Башкортстан:

– Чакмагыш районы музее директоры булып эшлим, шул ук вакытта районыбыз тарихын да өйрәнәм. Бездә туган якны өйрәнү ике зур юнәлештә бара. Беренчесе – борынгы тарихны язу. Икенчесе – биобиблиографик жанр. Мин икенчеләре рәтенә керәм, районның титуллы кешеләре турында язам. Бөек Җиңүнең 70 еллыгы алдыннан ике томлык чыгардык, хәзер дә шул эшне дәвам итәбез. Сугышка киткәннәрнең картотекаларын киңәйтеп, биографияләрен язабыз. Финанс ягына килгәндә, китаплар иганәчелек ярдәме белән чыгарыла. Район хакимиятендә дә аңлау бар, булышалар.

# Пенсионерларны нәрсә борчый?

**Пенсия – мәңгелек темадыр, мөгаен. Бу өлкәдәге үзгәрешләр турында күпме генә язылса да, Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге белгечләре көн саен халыкны кызыксындырган сорауларга җавап биреп торса да, аларның бетәсе юк. «Бердәм Россия» партиясенең төбәкара иҗтимагый кабул итүләр бүлмәсендә дә нәкъ менә шул темага сөйләштеләр. Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге җитәкчесе Эдуард Вафин, аның урынбасары Асия Вәлиуллина, Дәүләт Советы депутаты, «Бердәм Россия» партиясе рәисе Дмитрий Медведевның Татарстандагы төбәкара иҗтимагый кабул итүләр җитәкчесе Татьяна Воропаева пенсия өлкәсенә кагылышлы сорауларга җавап бирде.**

Автор фотосы

### «КОНВЕРТ»ТАГЫ АКЧАЛАРГА КЫЗЫКМАГЫЗ

– Мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе пенсиянең аз булуыннан зарлана. Законнарны, үзгәрешләрне аңлап бетермәү очраклары күп. Шуңа да һәр кешегә барысын да җентекләп аңлатырга тырышабыз, – ди Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге җитәкчесе урынбасары Асия Вәлиуллина.

Рәшидә ханым Сәгыйтова да нәкъ менә пенсиясенең сигез мең тирәсе генә булуыннан зарланып килгән. «Әллә дөрес исәпләмәделәрме икән?» – дип шикләнә ул. Югыйсә, 40 елдан артык стажы бар. Озак еллар укытучы булып эшләгән, соңрак үз бизнесын булдырган.

– Шәхси эшмәкәрләр белән һәрчак шундый нәрсәләр килеп чыга. Аларның күбесе Пенсия фондына аз кертем түли йә бөтенләй түләми. Нәтиҗәдә, картлык көнендә аз пенсия ала, – ди Асия Вәлиуллина. Фатирлар ремонтлап йөрүче бер егетне мисалга китерде ул.

– Гомер буе мондый эшне башкару мөмкин түгел, пенсиягә чыкканда, бу егеткә бернинди дә акча түләнмәячәк. Хезмәт хакыннан иминият взносы тотылмый икән, димәк, киләчәктә пенсияң дә юк дигән сүз. Яшьләр «конвертта»гы хезмәт хакына кызыкмасыннар иде, – дип кисәтә пенсия бүлегендәгеләр.

Стажга килгәндә, яңа кагыйдәләр нигезендә, пенсияне билгеләгәндә, 2002 елның 1 гыйнварына кадәрге еллары гына исәплиләр. Пенсияне формалаштырганда, 2002 елдан соң иминият кертемнәре генә кушыла. Шул рәвешле, кеше 30-40 ел эш стажым бар дип уйласа да, пенсиянең күләмен билгеләгәндә, 2002 елга кадәрге стаж гына мөһим. Закон нигезендә, 2002 елдан пенсия нәкъ менә хезмәт хакына бәйле булып чыга. Хезмәт хакы зуррак булган саен, пенсия фондына күчерелгән суммалар да зуррак.

### ДАРУ УРЫНЫНА АКЧА

Рафил абый Садыйков социаль пакеттан баш тартырга дип килгән. Баксаң, ул үзенә тиешле даруларны ала алмый башлаган икән. Чөнки вакытында участок терапевтына языла алмый, белгечкә килгәч тә, ул ташламалы дарулар исемлегенә кермәгән препаратлар язып биргән, имеш. Хәзер менә аңа ике мең сумнан артык дару таләп ителә, ә алар социаль пакет буенча каралмаган. «Шуңа да акчасын алсам отышлырак», – дип саный Рафил абый. Дөрес, социаль хезмәтләр җыелмасын ни рәвешле алуны халык үзе хәл итә. Әмма быелгысы инде хәл ителгән. Хәзер үзгәртеп булмый. 1 октябрьгә кадәр теркәлү урыны буенча Пенсия фондына гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, 2018 елдан дару урынына акча китерә башлыйлар. Социаль хезмәтләр җыелмасы медицина өлкәсендәге ташламаларны, санитар-курорт дәвалануы һәм транспортта йөрү хокукын үз эченә ала. Бүген социаль хезмәтләр җыелмасының айлык бәясе – 995 сум 23 тиен.

– Миңа Баулыдан бер кеше шалтыратты. Ул, киресенчә, акча урынына социаль җыелма алырга тели. Көтмәгәндә анда яман шеш барлыгын ачыклаганнар. Хәзер миллион сумнан артык акча кирәк, ди. Әмма, закон нигезендә, ничек алуны елга бер тапкыр гына сайларга була, шуңа ныклап уйларга кирәк, – ди Асия Вәлиуллина.

«Халыкны социаль яклау турында»гы федераль законга 2005 елда үзгәрешләр кертелгәннән соң, социаль хезмәт күрсәтү буенча вәкаләтләр субъектларга тапшырылды, һәр төбәк үз мөмкинлекләреннән чыгып эшли башлады. «Халыкны социаль яклау турында»гы законның төп максаты – Россия территориясендә халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең бердәм нормасын булдыру. Кеше билгеле бер таләпләргә җавап биргән очракта гына социаль хезмәткә мохтаҗ, дип табыла. Социаль пакет беренче чиратта Бөек Ватан сугышында катнашканнарга һәм сугыш инвалидларына, хәрби хәрәкәттә катнашканнарга, сугышта яралану чыларга бирелә. Шулай ук блокадалы Ленинград яшәүчесе билгесе булганнарга, вафат булган ветераннар, хәрби хәрәкәт сугышчыларының гаиләләренә, авыру, җәрәхәтләнү, яшь яки инвалидлык буенча үз-үзенә хезмәт күрсәтү мөмкинлеген тулысынча яки өлешчә югалтучыларга, шул исәптән инвалид балаларга да социаль ярдәм җыелмасы тиеш.

### БИРГӘНДӘ – ЗАРЛАНМЫЙЛАР

Рәдиф Хәбибуллин Биектау районыннан кадәр килгән. Аны хатыны Кәүсәрия апаның пенсиясендәге үзгәрешләр борчый. Хатыны пенсияне дәүләт финанславы (государственное софинансирование пенсии) программасында катнашкан булган. Бүген бу программада катнашып булмый, шулай да аның нинди схема буенча эшләвен аңлатып узыйк. Кеше Пенсия фондына кимендә ике мең сум акча түли, ә дәүләт аларның индивидуаль счетларына тагын ике мең сум өсти һәм, шулай итеп, ел дәвамында керткән 12 мең акчаны 24 мең итеп кайтарырга була. Кәүсәрия апа өч ел дәвамында 30 меңнән артык акча кертә. Инде, ниһаять, түбәне ремонтлау өчен акча булды дигәндә генә, кагыйдәгә үзгәрешләр кертелә. 2015 елдан соң бу акчаларны, элеккеге кебек, берьюлы алып булмый. Бары биш елга бер генә тапкыр алырга мөмкин. Кәүсәрия апага исә акчаларын ун елга бүлеп түләргә булганнар. Хәбибуллиннар монысы белән дә килешкән. Әмма бу акчалар пенсиягә өстәлгәннән соң, Кәүсәрия апаны федераль социаль түләүләрдән мәхрүм иткәннәр. Чөнки әлеге федераль түләүләр бары айлык пенсия яшәү минимумы 8232 сумнан ким булганда гына бирелгән. Хәбибуллиннар моның белән килешмәсә дә, законны үзгәртеп булмый.

– Дәүләт биргәндә, беркем шикаять белдерми, башка бирә алмый икән, зарланырга тотына. Бу дөрес түгел, – ди Татьяна Воропаева.

Шулай да бу сорауны социаль сәясәт комитетына юлларга, пенсионерга ярдәм итү юлларын эзләргә вәгъдә бирде.

Кабул итү бүлмәсенә килүчеләр арасында төрлесе бар. Кайсы сырхауханәдәге белгечләргә вакытында языла алмавыннан зарлана, кемнедер социаль ташламаларның түләнмәве борчый, «Пенсиямне үлемтеккә җыям, сәламәтлегем юк», – дип зарланучылар да бар. Бер хатын бөтенләй спектакль куеп чыгып китте.

– «Оливье» салатының исен дә, тәмен дә, анда нәрсә кушылганын да белмим. 76 яшемә җитеп, иремнең пенсиясенә 300 сум булса да өсти алмассызмы икән, дип килдем. Бәлки шул акчага «Оливье» ашап карар идем, – ди ул.

Кулындагы дүрт алтын балдагын, пенсия кенәгәсендәге акчасын күреп, бу хатынга нәрсә әйтергә дә белмәссең.

Пенсия өлкәсенә кагылышлы сорауларыгызны Россия Пенсия фонды Татарстан бүлегенең «кайнар элемтә» телефоны – **279-27-27** номеры аша юллый аласыз.

**Эльвира МОЗАФФАР.**

---

**БЕЛЕП ТОР!**

**Россия премьер-министры Дмитрий Медведев «Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә үзгәрешләр турында»гы карарны имзалаган, дип хәбәр итә INTERFAX.RU агентлыгы.**

## Билгең булмаса, йөртмә

Яңа канунннар нигезендә, машина йөртү стажы ике елдан артмаганнарга чикләүләр каралган. «Чәйнек»ләргә аерым очракларда транспорт чараларын буксирга алу, мототранспортта пассажирлар йөртү, зур күләмле, авыр һәм куркыныч йөк төялгән транспорт чаралары белән идарә итү тыела. Шулай ук хәзер рульгә яңа утырганнарга машинага махсус билге дә беркетергә туры киләчәк. Өндәү формасындагы «Рульдә күптән түгел» билгесе юк икән, «чәйнек»ләргә транспорт чараларын эксплуатацияләү тыела. Мондый хокук бозу өчен ЮХИДИ хезмәткәрләре аларга карата административ җаваплылык та билгеләргә мөмкиннәр. Юл йөрү кагыйдәләрендәге бу үзгәрешләр яңа гына машина йөртү таныклыгы алып, рульгә утырганнар катнашындагы юл һәлакәтләрен киметү өчен эшләнгән.

**АБАУ**

## Ит яхшылык – көт явызлык икән

**Узган шимбәдә Чаллы шәһәрендә, биш айлык балага ярдәм кирәк дип, «Ашыгыч ярдәм» хезмәтен чакырталар.**

Медицина хезмәткәрләре килеп җиткәндә, өйдә баланың әтисе һәм туган тиешле апасы гына була. Исерткеч әчемлекләр кулланып шактый кәефләнеп алган бу кешеләр баланы тикшерә башлаган медицина хезмәткәрләре белән бәхәскә керә. Хатын фельдшерга пычак белән һөҗүм итә. Зыян күргән хезмәткәрне сырхауханәнең хирургия бүлегенә озаталар. Әлеге эшне Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин үз күзәтүенә алды. «Зыян күргән фельдшерның гомеренә куркыныч янамый. Аңа бар яктан да ярдәм күрсәтеләчәк», – диделәр министрлыкта.

Әлеге факт буенча тикшерү органнары җинаять эше кузгаткан, дип хәбәр итә Татарстан прокурорының өлкән ярдәмчесе Руслан Галиев. Тикшерү барышында ачыкланганча, баланың әнисе берничә көн өйгә кайтмаган булган.

Бу хатын элек тә хөкем ителгән, наркотикларга кагылышлы эш буенча хокук саклау органнарында исәптә дә тора икән. Хәзер гаиләнең социаль хәле тикшереләчәк. Хокук бозу очрагы ачыкланса, прокуратура тарафыннан катгый чаралар күреләчәк.

Баланы, сәламәтлеген тикшерү өчен, сырхауханәгә салганнар.

ХАТЫН-КЫЗЛАР КОЛАГЫНА

# Сыйфатлы тун «чиплаштырылган» була

**Ниһаять, кышкы киемнәрне ераккарак алып куяр вакыт та җитте кебек. Ә тун сайлау темасы һәрчак актуаль. Сезон узгач, кышкы киемнәргә ташламалар башлана дип, күпләр тунны нәкъ менә яз, җәй алып калырга ашыга. Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе белгечләре тун сатып алганда нәрсәгә игътибар кирәклеге хакында сөйләде.**

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Эльвира МОЗАФФАР

Татьяна Ефименко да нәкъ менә сезон узгач, тун алуны отышлы дип саный.

– Кешедә булмаган үзенчәлекле тун эзлим. Бүген теләгән кешегә чәшке белән челтәр кушылган, төрле тукымалардан тегелгән гадәти булмаган өс киемнәрен алырга була. Бәясе ягыннан да күп кибетләрдә ташламалар каралган. Өлешләп түләү дә тәкъдим ителә. Бары сыйфаты гына ышанычлы булсын, – ди Татьяна.

Сыйфат – чынлап та мөһим нәрсә. Еш кына, тунның йоны коела, төсе үзгәрә, дип зарланучылар бар. Россиядә мех эшләнмәләре базарында тәртип урнаштыру, ялган товарны киметү максатыннан, былтырның языннан туннарны «чиплаштыра» башлаганнар.

Туннарга сугылган контроль идентификация билгесе (контрольный идентификационный знак –КиЗ) – төп сыйфат күрсәткече булып тора.

– 5 декабрьдән һәр тун җитештерүченең дә товарында КиЗ булырга тиеш. Кесә телефонына бушлай урнаштырырга мөмкин булган махсус кушымта ярдәмендә шул КиЗны сканер аша төшереп, тун турында тулы мәгълүмат алырга була. Анда киемне кем җитештергәне, ул кайда тегелгәне, буялганмы, юкмы икәнлеге, нинди тукымадан булуы турында мәгълүматлар тупланган, –ди Роспотребнадзорның кулланучылар хокукларын яклау бүлегендә баш белгеч, эксперт Оксана Семушина.

Быел Роспотребнадзорның Татарстан идарәсенә туннар сыйфатына кагылышлы алты шикаять кабул ителгән. Аларның дүртесе Казан фирмаларына кагыла. Бу очракта Таможня берлегенең «Җиңел сәнәгать продукциясе куркынычсызлыгы турында»гы техник регламент буенча таләпләр үтәлмәве ачыкланган. Ә калган ике шикаять Яшел Үзән һәм Бөгелмәдәге тун сату кибетләренә карый. Биредә товарлардагы контроль идентификация билгесенә тиешле барлык мәгълүмат та кертелмәгән булган. Әлеге ике очрак буенча административ эш ачылган.

Оксана Семушина аңлатуынча, тун сыйфаты сатып алучыны канәгатьләндерми икән, гарантия буенча, Россиядә кулланучылар хокукларын яклау турындагы закон нигезендә, ул аны шундый ук товарга алыштыра йә акчасын кире кайтара ала. Бу очракта кимчелек өчен сатучы җавап бирә. Әгәр гарантия вакыты узганнан соң тунны кире кайтарырга туры килсә, махсус экспертиза тикшерүе уздырыла. Монда инде барлык чыгымнарны да экспертиза оешмасы каплый. Товарда тиешле контроль идентификация билгесе булмаганда, шәхси эшмәкәрләргә 5-10 мең, юридик затларга 50-300 мең штраф каралган. Әгәр тәртип бозу кабатлана икән, Роспотребнадзор идарәсе әлеге фирманы ябу турында судка иск тапшыра ала.

**ТУН САЙЛАУЧЫГА «МЕЛИТА» СӘҮДӘ ЙОРТЫНЫҢ ГЕНЕРАЛЬ ДИРЕКТОРЫ АЛСУ ХӘЛИУЛЛИНА КИҢӘШЛӘРЕ**

- ✓ Тунны сыйпап карагыз, ул тавыш чыгарырга, кыштырдарга тиеш түгел.
- ✓ Йоны йомшак, сыгылмалы булсын, ялтырап торсын.
- ✓ Тунны кулыгыз белән сыпырыгыз, йоны учта калмаса яхшы.
- ✓ Киемне бары гарантия бирә торган танылган брендлы, ышанычлы кибетләрдән генә алыгыз .
- ✓ Фабрикада ГОСТ таләпләре буенча тегелгән туннан да сыйфатлысы юк.

**Кичә Дәүләт Думасына суррогат ана булуны тыйган закон проекты кертелде, дип хәбәр итә «Известия».**

## Суррогат аналар тыелырмы?

Әлеге тәкъдимнең башында сенатор Антон Беляков тора. Аның фикеренчә, Россия «репродуктив» туристлык иленә әйләнде, тик әлеге бизнеста катнашучыларның мөнәсәбәтләре дәүләт тарафыннан каралмый диярлек. Нәтиҗәдә, суррогат аналар, генетик ата-аналар һәм шушы рәвешле туган балалар тиешле юридик яклау ала алмый. Урыс православ чиркәве әлеге карар проектын хуплый, әмма табиблар һәм юристлар моны тыюга каршы.

Бүген Россиядә суррогат ана булу гражданлык-хокукый килешүе буенча оештырыла.

– Ул бурычлар һәм хокукларны карый, әмма аларның катгый үтәлешенә гарантия булмый, – дип үз тәкъдимен нигезли Антон Беляков. – Бала патология белән туса яки карында килеш үлсә, бу килешү үтәмәү буламы? Әлеге сорау да ачык кала. Баланы суррогат анадан ата-анасына тапшыру өчен «заказчы»дан уллыкка алу процедурасын үтәү дә таләп ителми. Шул ук вакытта, Россия Гаилә кодексының 4нче булеге 51нче маддәсе нигезендә, биологик әти-әниләр сабыйны бала тудыру йортыннан суррогат ана рөхсәте белән генә алырга мөмкин. Бу еш кына суррогат аналарның биологик ата-аналарга басым ясау мөмкинлеген тудыра.

Россиядә суррогат аналар институтына карата яңа, комплекслы алым ясалганчы, аны тыярга кирәк, дип саный Антон Беляков.

# «Яшел елан» сабыйлардан ерак торсын

**Элеккеге заманнарда ата-аналар мәҗлес корган табынга кечкенә балаларны якын да китермәгән. Бүген балалар – аракылы табын түрендә.**

Дамир БӘДРИЕВ

Быелның февраль аенда республикада алкогольдән һәм спирт катнашмалы эчемлекләрдән 36 кеше агуланган.

– Әлеге агуланучыларның 5,6 проценты – балалар. Сусаган сабыйлар спиртлы эчемлекне белештермичә эчә. Ахыры аяныч: ияләшмәгән яшь организм агулана, – дип борчылып кисәтте Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Миләүшә Җәләлиева.

Узган ел алкогольдән һәм спирт катнашмалы эчемлекләрдән 776 кешенең агулану очрагы теркәлгән, шуларның 82,9 проценты – ир-атлар. Роспотребнадзор хезмәте белгечләре әйтүенчә, үсмер чактан ук спиртлы эчемлекләрне күп эчү организмда каты авырулар кузгатырга, нәсел дәвам итү яки бала таба алу сәләтен юкка чыгарырга мөмкин. Әгәр гаилә буыннан буынга эчкечелек белән шөгыльләнсә, икенче-өченче буыннарда гарип яки психик авырулы сабыйлар туа башлаячак.

Бөтендөнья Сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, кеше елына сигез литрдан артык алкоголь кулланса, бу – организмга зыян салуга керешү. Россиядә 2009 елда кулланылган спиртлы эчемлекләр кеше башына 15 литр туры килгән. Шөкер, россиялеләр үз сәламәтлеген кайгыртырга керешкән дип уйларга була. Үткән ел кулланылган спиртлы эчемлекләр һәр кеше исәбенә 10 литр туры килгән.

Татарстан буенча Дәүләт алкоголь инспекциясе идарәсе белгечләре кисәтүенчә, иң куркынычы – спирт катнашмалы сыеклыклар эчү. Агуланып үләсең килмәсә, автомобиль тәрәзәсе юдыргычларын, җитештерүчесе яки составы билгеле булмаган спиртлы эчемлекләрне, гигиена максатларында куллану өчен чыгарылган спирт катнашмалы продукцияне эчәргә һич кенә дә ярамый.

Россиядә 22.00 сәгатьтән башлап, иртәнге 10.00 сәгатькә кадәр алкоголь продукциясе сату тыела. Мәгариф, медицина учреждениеләренә якын урыннарда, шулай ук лицензиясез килеш җәмәгать туклануы предприятиеләрендә спиртлы эчемлекләр сатарга ярамый. Идән астында этил спирты җитештерү һәм сату, башка өлкәләрдән (чит илдән) яшертен рәвештә спирт, спирт катнашмалы сыекчалар алып кайту закон бозу булып санала. Шушы таләпләрне бозучыларны фаш итүдә катнашкан кешеләргә Татарстан буенча Дәүләт алкоголь инспекциясе 1-3 мең сум күләмнәрдә акчалата түли.

Моның өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында https://uslugi. tatarstan.ru/ теркәлергә һәм закон бозу фактын «Халык контроле» («Народный контроль») адресына җибәрергә кирәк.

# Милли моң сакчысының берсе

**Быел Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә дәгъвалаучылар (Аллага шөкер, барысы да ихтирамга лаек шәхесләр, мәгълүм иҗат әһелләре!) арасында – инде күптән җаным теләгән исемне – рухыма якын җырчым, Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗановны да күреп, бик сөендем.**

Нигәме? Казахның зур шагыйре Мукагалинең (шушы көннәрдә генә Роберт Миңнуллин тәрҗемәсендә, аның татарча китабы да дөнья күрде) «Минем анкетам» дигән шигырендә, «Туган илың?» дигән сорауга ел-датасы күрсәткәч, «кордашымын Шамилнең!» – дип өстәгән. Кем икән ул Шамил? Белмим. Әмма мин шундый анкета-шигырь язсам, шагыйрьләр белән бергә танылган җырчы Шамилебезне дә әйтер идем. «Яшьтәшемен, кордашымын Шамилебезнең», – дип. Әйе, иҗаты, безнекедәй, узган гасырның 60нчы елларында ук башланган Шамил Әхмәтҗанов белән без яшьтәшләр, 41нче елгылар. Гүяки арыш басуында – изге моңнар туфрагында туып-үскән, чын милли бишек – авыл балалары без! «Кайда да йөрәктә, төшләргә кереп гел йөдәтә Кырлай яклары» дип юкка гына җырламый Шамил. Әйе, ул Арча ягыннан, мәгърифәтче муллалар һәм атаклы көрәшчеләр белән дан тоткан Курса Почмак авылыннан. Тукай туган як бу, Курсавилар, Мәрҗаниләр, Камаллар чыккан төбәк. Шул данлы якташлары кебек, бүген халыкка танылу өчен, әлбәттә, алар рухын, моңын тоярга, дәвам итәргә, гомереңне шул юлга багышларга кирәк! «Бер генә аның шарты!» – ди бу турыда шагыйребез Сибгат Хәким, якташларының дәвамын кузаллап. Бөек миссия бу! Җырда да шулай. Сүз җаеннан әйтик, Сибгать ага Шамилне якын итә иде: иҗатын хуплап, мәкаләләр язды, киңәшләр биреп, уңышлары өчен сөенеп яшәде, иҗат кичәләренә чакырды. Бергә Күлле Кимегә кайтулар әле дә истә. Шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкарган Шамилнең моң аһәңнәре дә хәтердә. Тукаебыз сүзләренә җырлана торган җырлар да колагымда Шамил тавышы белән яңгырый: «Туган җиремә», «Зиләйлүк», «Әлвидагъ», «Өзелгән өмид...» һ.б. Сибгат Хәким сүзләренә «Бик сагынган чаклар була сине, Тукай» җыры да Тукайга бәйле. «Син чыгасың, әнкәй, коега» җыры да (Сибгат Хәким сүзләренә) халыкчан моң белән өретелгән. Чын безнеңчә матур милли көйләр, билләһи! Шамилнең ягымлы тембрлы баритон тавышы, ачык дикциясе, салмак эчке бер илаһият белән тәэсир итә торган интонацияләр, милизмы – барысы да шул вакыйгалардан алып күңелне әсир иткән, мөгаен. Җырчы белән күп кенә авылларда да йә Казанда узган шигырь, җыр кичәләрендә бергә чыгыш ясарга туры килде. Һәм аның уңышларының шаһиты булу бәхете дә тиде ул чакларда: гади халык мәхәббәте белән бергә төрле җитәкчеләрнең, ил агаларының, хәтта Илбашының да яратып кабул итеп, җырчыга ихтирамлы мөнәсәбәтен күреп, Шамил өчен һәрчак горурлык тойдым. Шулай, шагыйрьләр белән җырчылар дуслыгы да Тукай чорыннан ук килә бит: барыннан да бигрәк Моң өчен, халыкчан башкару мәктәбе, шул юлда бөек Илһамнар янәшәсендә үз йөзен югалтмаган чын табигый тавыш ияләре өчен горурлык хисе ул.

25 яшеннән башлап, җырчының хезмәт урыны – Татарстан җыр һәм бию дәүләт ансамбле. Татар исемен – моңын, рухын бар дөньяга таныту еллары бу. Үзе бер милли тарих булган – ансамбльнең эшчәнлегенә багышланган китапны укыганда да (моның өчен якташым Филүсә Арслановага рәхмәтлемен) Шамил өчен горурлык хисе ташламады: ул – ансамбльнең солисты, дуэт белән дә гаҗәеп матур язмалары калган (Ания Туишева белән бергә башкарган «Ак пирчәткә», «Галиябану»), «Таһир-Зөһрә» һ.б. искә төшерик. Ә халык җырларыннан инде Шамил башкаруында «Арча», «Сивай кашка», «Мөһаҗирләр», «Әрәмә», «Син дә җаныемның хәсрәтеннән», «Алма бакчасы», «Габделхәй» кебекләрне аерым әйтер идем. Алтын фондка кергән җырлар дип саныйм мин аларны. Җырчының 75 җырдан торган соңгы аудиодискында алар күп – җаның теләгәнен тыңла.



ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТ

Ә инде Шәриф Хөсәенов сүзләренә Рөстәм Яхин язган атаклы «Сорнай җыры» ансамбль белән ярты дөньяны гизгән. Нинди генә илләрдә алкышламаганнар Шамилне ул җыр өчен: Германия, Төркия, Япония, Италиядә, Африка... Ә Мәскәүдә? Югары сәнгать белгечләре нәкъ шунда олуг бәясен бирә җырчыбызга... һәм, әлбәттә, ансамбльгә. Рөстәм Яхинның башка җырларын да Мансур Мозаффаров, Сара Садыйкова,Фасил Әхмәтов, Мирсәит Яруллин әсәрләрен дә башлап җырлау бәхете тия Шамилгә һәм ул әле мәгълүм «Аулак өй» исемле вокаль-хореография спектаклендә (Нәкый Исәнбәт әсәре буенча куелган) җор, шаян Бабай ролендә дә 25 ел буе уйнап, танылу ала. Ә 1998 елда Түбән Новгородта узган халык җырларын башкару бәйгесендә (жюри рәисе Илһам Шакиров үзе!) лауреат исеменә лаек була. Җырчы бүген дә Моң илендә. Филармониядә вокал буенча репетитор. Яшь җырчыларның остазы. Шәкертләре – Рамил Миңнегалиев, Илнур Нуриев, Аршак Алтуняннар инде үзләре төрле конкурсларда җиңү яулаган сәләтле яшь талантлар. Әмма иң сөйгән укучысы – кече кызы Чулпан Әхмәтҗановадыр, мөгаен. Татарстанның атказанган артисты ул. Әтисенең юлын дәвам итүче җырчы. Өлкән кызы Гөлнар да музыкант-композитор. Менә шундый милли-музыкаль гаилә бар Казанда.

Халыкның рухы-күңеленең «рушан көзге»сен һәм туган телне нәкъ Тукай өйрәткәнчә аңлап, саклап, киләчәккә алып бара торган үрнәк мәктәп түгелмени бу иҗат?! Ә җыр дигән, моң дигән төшенчәләрнең әнә шундый сыналган, халыкчан традицияләргә таянуын еш кабатлап тору зарурдыр. Бигрәк тә бүгенге вазгыятьтә.

**Рәдиф ГАТАШ,**
Татарстанның
халык шагыйре.

ПОЧТАДАН

# Безнең китаплы Сөләйман

***Җитте шундый заман: татарның теле бетә дип оран сала башладылар. Их идрит-кудрит, тормышка керде шул интернет. Имеш, газета-журналларның көне санаулы гына, китаплар да, имеш, калыр чүплектә... Ашыкмасыннар! Андый көнгә калмабыз.***

Әнә Сөләйман Шакиров шалтырата, белеп торам, яхшы хәбәр әйтәчәк ул миңа. Театрларга йөрергә ярата ул. Әле «Җанкисәккәем»не, әле «Зәңгәр шәл»не, әле кичә генә «Җилкәнсезләр»не карарга чакырган иде. Бу юлы «Казан» милли мәдәният үзәгендә китап күргәзмәсе була дип җиткерде.

Сөләйман белән күптәнге дуслар: 1нче трестта 33 ел бергә эшләдек, 15 еллап Казан Аксакаллар шурасында фикердәшләр булып аралашабыз.

Сөләйман Шакиров «Тормыш мизгелләре» дигән китабын бастыргач, берничә көнгә дип кенә миңа укырга биреп торган иде. Өченче көн киткән икән, ярый әле укырга өлгердем. Шуны эләктердем дә йөгердем.

Сөләйман кордаш мине, вәгъдә иткәнчә, ишек төбендә каршы алды. Рәхмәт әйтеп, китабын тапшырдым. Тиражының 99ын туганнарына, Әлки төбәгендәге «Хузангай» хуҗалыгы җитәкчеләренә, китапханәләргә бик тиз таратып бетергәнгә, үзенә дә шул гына калган икән.

Залга уздык. Кулына китабын тоткан килеш, Сөләйман буш калган урынга килеп утырды. Урыннарыбыз өлкән журналист-язучы Азат Сөнкишев янәшәсенә туры килде. Сөләйманга Алиш баба оныгы – Абдулла Алишның кардәш туганы: «Син кем?» – дип сорау бирде.

– Сөләйман пәйгамбәр булган бит, – диде дустым. – Мин китаплы Сөләйман булам.

Болай дип әйтергә хокукы бар шул аның. Китап язу, бастыру хәлләренең ничеклеген миңа сөйләде ул. Китабына да язган. Әлки районы Татар Тәгәлбәендә туган ул. Шунда егет булып җитлеккән. Казанга барып укып кайтканнан соң туган авылында һәм Моркваши ял йортында халыкка кино күрсәткән. Хәтта авылларында клуб мөдире дә булган әле. 60-90нчы елларда Казандагы КПД – 1 заводында эшләгәндә, Сөләйман да хезмәттәшләре белән ярты Казанны төзеште. Китап язарлык багажы бар, диюем. Шуңа күрә дә Сөләйман кордашның әлеге китабы үзенең лаеклы бәясен алыр дип ышанам, чөнки аның Шакировлар гаиләсе өчен генә язылмавы күренеп тора.

Әлеге китапта Түбән Новгород өлкәсенең Сергач төбәгендәге бер авылында үткәрелгән татар Сабан туе турында матур хикәя бар. Сөләйман бу авылны, андагы кешеләрне барып күргәч, фотоларын да урнаштырган, чөнки бу авылда ул яраткан Хәсибә исемле кыз үскән. Һәм аның гомерлек яры булган. Алар бергә-бергә шул Сабан туйларын күреп йөргән. Ул үз китабында туган төбәге Әлкидәге Актай, Бизнә елгаларын, челтерәп аккан чишмәләрен, Салман, Чаллы, Әлки авылларын да яратып тасвирлаган. Аның өчен киң Ватаныбыздагы бөтен җир – газиз. Андагы чуаш, урыс татар авыллары дисеңме, барысы да күңеленә якын. Ул яхшы гамәл кылган бар кешене дә ярата, хөрмәт итә.

Нәрсә әйтим, бер утырыду рәхәтләнеп укый алырлык китап язган быел 80 яшен түгәрәкләүче дустым. Үзенә генә түгел, Казан аксакалларының күбесенә, милләттәшләренә дә әлеге китабы белән матур бүләк ясаган кордаш. Рәхмәт үзенә!

**Рәис ИДРИСОВ.**

# Өметле композитор

**Казанда язучы Василий Аксенов музеенда төрле әдәби кичәләр, концертлар уза. Шундыйларның берсе композитор Рушания Ниҗәметдиновага багышланган иде.**

Яшь композитор Рушания Ниҗәметдинова Мәскәү консерваториясен тәмамлаган. Аның әсәрләре Казан, Санкт-Петербург, Германия, Бөекбритания, Испания һәм Мәскәүдә халыкара фестивальләрдә яңгырый. Бүгенге көндә ул электроакустик һәм акусматик музыка белән шөгыльләнә, музыка мәктәбендә укыта. Кичәдә дә аның әсәрләрен халыкара конкурслар лауреатлары, Нәҗиб Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе студентлары башкарды. Шагыйрь, журналист Айрат Бик-Булатов үзенең шигырьләрен укыды.

**Равилә МӨБАРӘКШИНА.**

# «ТАНТАНА» тантана итте

Люция ГАЛИМҖАНОВА

мәдәният

Кичә Камал исемендәге театрда «Тантана» театр премияләре тапшырылды. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм күрсәтү фондының махсус бүләге белән Бөгелмә рус драма театрыннан «Иң яхшы режиссер эше» дигән төрдә Рөстәм Фәйзрахманов бүләкләнде. «Сәхнә» журналының махсус бүләгенә Туфан Миңнуллинның «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» комедиясенең заманча укылышы өчен Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры режиссёры Резедә Гарипова ия булды. «Үзгәреш җиле» Татар җыры фестивале» проектын уңышлы тормышка ашырулары өчен Рәүфәл Мөхәммәтҗанов җитәкчелегендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры коллективы бүләкләнде. «Иҗади үсеше өчен» махсус номинациясенә – Яшел Үзән музыка театры, Түбән Кама яшь тамашачы театры, Динара Әхмәтова (Минзәлә театры) лаек дип табылды.

«Намус һәм тугрылык» номинациясендә бүләк Яр Чаллы Татар дәүләт драма театрыннан Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Инсаф Фәхретдиновка тапшырылды.

«Ел вакыйгасы» номинациясендә Илгиз Зәйниевнең «Сак-Сок» спектакле өчен Яр Чаллы дәүләт курчак театры бүләкләнде. «Балалар өчен иң яхшы спектакль» номинациясендә «Тапкыр Кәҗә турында әкият» спектакле өчен Минзәлә Татар дәүләт драма театрына тапшырылды. «Иң яхшы эпизод роле» номинациясендә Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачылар театрының «Артист» (Ркаил Зәйдулла) спектаклендә Әби роле өчен Татарстан Республикасының атказанган артисты Алия Кәлимуллина бүләкләнде.

Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә бүләккә Камал театрыннан («Җилкәнсезләр» спектаклендә Нуретдин роле өчен) Татарстанның атказанган артисты Рамил Вәҗиев лаек булды. «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә Әлмәт театрыннан Татарстанның атказанган артисты Наилә Нәҗипова («Син кайда идең?» спектаклендә Эльза Александровна роле өчен), «Курчак театрының иң яхшы артисты» номинациясендә «Әкият» Татар дәүләт курчак театрының «Бүре җиләге» (Ркаил Зәйдулла) спектаклендә Елгыр роле өчен Татарстанның атказанган артисты Фәнзилә Сабирова бүләкләнде. «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә бүләкне Камал театрыннан Татарстанның халык артисты Искәндәр Хәйруллин («Җилкәнсезләр» спектаклендә Мисбах хаҗи роле өчен) яулады. «Дебют» номинациясендә Буа театрыннан Илсур Мортазин һәм Әлмәт театрыннан Диләрә Ибәтуллина бүләкләнде.

Чарадан фоторепортаж
www.shahrikazan.com
сайтында

# «Мураками» Казанга кайтты

**Япон исемле булса да, Казанда туган «Мураками» рок-төркеме менә 13 ел инде популярлыгын югалтмый. Әле күптән түгел генә алар илебезнең 45ләп шәһәрендә булып, Байкалга, Ерак Көнчыгышка кадәр барып, иҗатларын тамашачыга җиткереп кайтканнар.**

Шуңа күрә дә журналистларга да сөйләр сүзләре, сәяхәттән алган тәэсирләре күп аларның. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясенә әлеге төркемнең музыкантлары – Иннокентий Минеев, Антон Кудряшов, Раил Латыйпов, Алексей Конев һәм Диләрә Ваһапова уңышларының сере һәм киләчәк планнары белән уртаклаштылар.

– Казанда ай саен бер-ике көннән артык тора алганыбыз юк, – диде төркемнең директоры һәм барабанчысы Иннокентий Минеев.

Бигрәк тә Мәскәү һәм Питер тамашачысы сокландырган аларны. Архангельск һәм Ярославль тамашачысыннан да бик канәгать калганнар. Ә менә Казанда рок концертлар өчен клублар юк дигән фикердә алар.

Диләрә Ваһапова әлеге төркемнең солисты һәм җыр текстларының авторы да. Күптән түгел генә аның икенче шигырь җыентыгы дөнья күргән. Җырның сүзләрен Диләрә язса, көен төркемнең егетләре иҗат итә.

Популярлык биеклегендә калыр өчен, аларга экспериментлар да ясарга туры килә. Яңа программаларында тамашачыга 25 минут буе биергә мөмкинлек тудырганнар – ритмлы алты җыр бертуктамый берсе артыннан берсе яңгырый, ди.

Тиздән Киевта булачак «Евровидение» тирәсендә чыккан ыгы-зыгы турында да сорау булды.

– Хәтта сәнгатьнең дә сәясәтләштерелүе бик кызганыч, – диде музыкантлар.

Бу төркем яшь рок музыкантларга да һәрдаим ярдәм итә. Казан дәүләт энергетика университетында узган торган «Рок энергиясе» фестивале алар ярдәме белән уңышлы үткәрелеп килә.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

**Рәшит Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыр фестиваленең яшь башкаручылар конкурсына гаризалар кабул итү 1 апрельгә кадәр дәвам итә. Быел сайлап алу турлары ике шәһәрдә үткәрелә: 11 апрельдә – Уфада һәм 13, 14 апрельдә – Казанда.**

## Әле өлгерәсез

Яшь җырчылар «халыкчан башкару», «академик җырлау», «эстрада», «вокаль ансамбль» юнәлешләрендә талантларын күрсәтәчәк. Абруйлы жюрины быел исә дөньякүләм танылган җырчы Ренат Ибраһимов җитәкли. Күп еллар дәвамында конкурсның жюри рәисе булган Илһам Шакиров та Ваһапов фестиваленнән читтә калмый. Киләчәктә ул конкурсның мактаулы рәисе булачак.

Җиңүчеләр тантаналы рәвештә 15 майда Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Ваһапов фестиваленең гала-концертында игълан ителәчәк.

Конкурска кагылышлы тулырак мәгълүматны Ваһапов фестиваленең рәсми төркемендә табарга була.

# «Туганнарны күргәндәй булабыз»

**10-16 апрельдә Камал исемендәге театрда Башкортстанның Гафури исемендәге театр артистлары гастрольләре уза.**

– Без Камал театрына гастрольләргә килгәч, туганнарыбыз белән күрешкәндәй булабыз. Ике театр арасында артистлар белән дуслык элемтән саклана. Репертуардагы сигез спектакльнең икесе балалар өчен сайланган. Арада Фәрит Бикчәнтәев барып сәхнәләштергән «Антигона» спектакле дә бар. Фәрит үз талантын безнең белән дә бүлеште. Нәтиҗәдә кызык кына спектакль туды. Анда 57 кеше катнаша, – ди театрның сәнгать җитәкчесе Олег Ханов.

– Миңа бу спектакльне кую кызык булды. Артистлар белән эшләү авыр түгел, чөнки труппа бик әйбәт. Өлкән артистлар да, яшьләр дә әзерлекле, – диде Фәрит Бикчәнтәев.

Ул, 2019 елда узачак «Нәүрүз» фестивален театрларының 100 еллыгы уңаеннан Башкортстанга багышларга кирәк, дигән тәкъдимен дә җиткерде.

Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәре буенча спектакль куярга җыенуын да хәбәр итте Олег әфәнде.

Гафурилылар үзләренең чыгышларын 10 апрельдә «Каһым түрә» спектакле белән башлый.

– Һәркем үзенең тарихын белергә тиеш. Каһым түрә ул – безнең халкыбызның баһадиры. Аның турында халкыбыз җыр, бәетләр чыгарган. Без бу хакта сөйләргә тиеш. Мин анда төп рольдә уйныйм. Спектакльдә шулай ук халыкның яраткан артистлары Гөлли Мөбарәкова, Азамат Гафаров һ. б. уйный, – дип сөйләде Разифә Динмөхәммәтова.

Спектакльләрдә тамашачы Фидан Гафаров, Нурия Ирсаева кебек мәшһүр артистларны да күрә алачак.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ВАЗИФАСЫН БАШКАРУЧЫ
Илсөяр Илфруз кызы Вәлиуллина.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – Расиха Габделбәр кызы Исмәгыйлова.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1668. Гомуми тираж – 6338.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 693. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур.,
2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы